## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
## МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 1 29 гыйнвар 2015 ел

**Мюд авыл җирлеге Башкарма комитет**

**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының**

**2014 елгы җирлекнең социаль-икътисадый**

**үсеш нәтиҗәләре буенча һәм 2015 елга фараз турында хисабы**

Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручының 2014нче елдагы социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2015 елга фараз турында тыңлап фикер алышканнан соң. Авыл җирлеге советы 2014 елда җирлек халкы мәнфәгатьләрендә эшләр башкарды, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге Советы КАРАР кылды:

1. Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Зюзина Татьяна Викторовна хисабы. 2014 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2015 елга фаразны игътибарга алырга.
2. 2015 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсешенең төп бурычы- халыкның тормыш сыйфатын үстерүне тәэмин итү.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирү.
4. Яшьләрне авылга беркетү өчен кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә тормышка ашырыла торган программалар мөмкинлекләреннән файдаланырга.
5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен киметмәү һәм гражданнарның социаль хезмәтләрдән тигез файдалануын тәэмин итү буенча чаралар күрү.
6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү һәм гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм абруен ныграк яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын дәвам итү.
8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне гомумиләштерергә
10. . Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.
11. . Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мюд авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
БашлыгыУрынбасары А.Г.Семенушкин